**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "БОЛГАР ШӘҺӘРЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№ 38-4** **«14» май 2024 ел**

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 22 ноябрендәге 12-3 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2024 елның 06 мартындагы 36-2 номерлы үзгәрешләре белән).

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" Татарстан Республикасы Законына, "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге Советына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 09 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 12-3 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2024 елның 06 мартындагы 36-2 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. III бүлекнең 10 өлешендәге 10.1 пункты түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчасы белән тулыландырылырга:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, аларның үзгәрүе яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча булган белешмәләрдән тыш (алга таба - анкетадагы белешмәләр)»;

1.2. III бүлекнең 11 өлешендәге 11.1 пунктының 8 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелергә тиеш:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны узу чорында ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, йә документларны һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмау, аларны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында дәлилләүче документлар һәм (яисә) белешмәләрне тапшырмау;»

1.3. IV бүлекнең 16 өлешендәге 16.3 пунктының 2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелергә тиеш:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета»;

1.4. VIII бүлекнең 27 өлешендәге 27.2 пунктының 11 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелергә тиеш:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәрләргә узган вакытта граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында (/http:pravo.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Болгар шәһәр башкарма комитетына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районының
"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы Ф. В. Мөхәммәтов